**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Куян торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

№1 09 ноябрь 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ атарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 09 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде: 2023 елда Минзәлә муниципаль районының Бикбау авыл җирлеге Куян торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2500 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

- Куян торак пунктында Совет урамының калган өлешенә вак таш сатып алу һәм салу (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 30 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 17 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде 17 халык җыенында катнашучылар;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Куян торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләре дөрес дип игълан итергә.

Сорау буенча карар кабул ителде дип танырга: 2023 елда Минзәлә муниципаль районының Бикбау авыл җирлеге Куян торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2500 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 төркем инвалидлардан, Бөек

Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

- Куян торак пунктында Совет урамының калган өлешенә вак таш сатып алу һәм салу (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

2. Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Бикбау авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә. http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.
3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Куян торак пунктында гражданнар җыенының әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ________________Л.Н. Мардамшина

Бикбау авыл җирлеге башлыгы: ________________Л. Н. Мәрдәмшина